| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1009

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 2015 ел, 23 сентябрь, 698 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 2015 ел, 23 сентябрь, 698 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карарга «Айлык акчалата һәм башка төрдәге түләүләр күләмнәре» кушымтасында:

| | |
|---|---|
| «хезмәт ветераннарына; | 427,0» |

юлын түбәндәге эчтәлекле юлга алмаштырырга:

| | |
|---|---|
| «мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына; | 427,0» |

| | |
|---|---|
| «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты хакында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган | 427,0» |

| | |
|---|---|
| пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү | |

юлын түбәндәге эчтәлекле юлга алмаштырырга:

| | |
|---|---|
| «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты хакында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү: | |
| мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре 20 000 сумнан артмаган; | 427,0 |
| мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре 20 000 сумнан артык булган | 280,0». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1009.docx